**ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Иске Кәшер авыл җирлегенең Анак авылы торак пунктында
2024 елда үзара салым кертү турында

**2024 елның 30 марты** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлеге башлыгынын 20.03.2024 ел 1 нче номерлы "«Иске Кәшер авыл җирлеге Анак торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлегенең Анак 2023 елның 17 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлегенең Анак торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлегенең Анак авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1.«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлегенең Анак авылы торак пунктында 2024 елда үзара салым кертү турында» 17 ноябрь 2023 елнын 2нче номерлы карарына узгәрешләр кертү турында чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«1. Анак авылындаэлектр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән җиһазларны (урам яктырту челтәрләрен ремонтлау (лампалар, таймерлар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру)

2. Анак торак пунктында торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (юлларны кардан чистарту (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү) ;

3. Анак торак пунктында янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын (гидрант урнаштыру (махсус техниканы арендалау, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү) төзү, ремонтлау);

4. Торак пункт территориясен төзекләндерү (җәйге вакытта территорияне чабу(килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү) Анак торак пунктында; бензокосилка, ЗИЛ-131 автомашинасы, Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу; Беларусь МТЗ 82.1 тракторы, ЗИЛ-131 автомашинасы өчен запас частьләр;

2. Әлеге карарны Иске Кәшер авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Иске Кәшер авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Дәүләтҗанов Р.Н.